**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# Об установлении запрета на привлечение в 2025 году хозяйствующими субъектами, осуществляющими деятельность на территории Республики Татарстан, иностранных граждан, осуществляющих трудовую деятельность на основании патентов, по отдельным видам экономической деятельности

В соответствии с пунктом 6 статьи $18^{1}$ Федерального закона от 25 июля 2002 года № 115-ФЗ «О правовом положении иностранных граждан в Российской Федерации», постановлением Правительства Российской Федерации от 7 декабря 2015 года № 1327 «Об утверждении Правил определения срока приведения хозяйствующими субъектами, осуществляющими деятельность на территории субъекта Российской Федерации, численности используемых ими иностранных работников в соответствие с запретом на привлечение такими хозяйствующими субъектами иностранных граждан, осуществляющих трудовую деятельность на основании патентов, по отдельным видам экономической деятельности, установленным высшим должностным лицом субъекта Российской Федерации (руководителем высшего исполнительного органа государственной власти субъекта Российской Федерации)» **постановляю**:

1. Установить, что до 31 декабря 2025 года включительно хозяйствующим субъектам, осуществляющим деятельность на территории Республики Татарстан, запрещается привлекать иностранных граждан, осуществляющих трудовую деятельность на основании патентов, по следующим видам экономической деятельности, предусмотренным Общероссийским классификатором видов экономической деятельности (далее – ОКВЭД):

перевозка опасных грузов (код по ОКВЭД 49.20.1);

деятельность легкового такси и арендованных легковых автомобилей с водителем (код по ОКВЭД 49.32);

деятельность по предоставлению финансовых услуг, кроме услуг по страхованию и пенсионному обеспечению (код по ОКВЭД 64);

страхование, перестрахование, деятельность негосударственных пенсионных фондов, кроме обязательного социального обеспечения (код по ОКВЭД 65);

деятельность вспомогательная в сфере финансовых услуг и страхования (код по ОКВЭД 66);

деятельность в области права и бухгалтерского учета (код по ОКВЭД 69);

деятельность ветеринарная (код по ОКВЭД 75);

деятельность охранных служб, в том числе частных (код по ОКВЭД 80.10);

деятельность по организации и проведению азартных игр и заключению пари, по организации и проведению лотерей (код по ОКВЭД 92);

ремонт компьютеров, предметов личного потребления и хозяйственно-бытового назначения (код по ОКВЭД 95).

2. Установить, что срок приведения хозяйствующими субъектами, осуществляющими деятельность на территории Республики Татарстан, численности используемых ими иностранных работников в соответствие с запретом, предусмотренным пунктом 1 настоящего Указа, для каждого вида экономической деятельности, указанного в пункте 1 настоящего Указа, составляет три месяца со дня вступления в силу настоящего Указа.

3. Настоящий Указ вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.

**Раис Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РАИСЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ

Казань, Кремль
29 января 2025 года
№ 57

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара торган хуҗалык субъектларына карата 2025 елда патентлар нигезендә икътисадый эшчәнлекнең аерым төрләре буенча хезмәт эшчәнлеге алып бара торган чит ил гражданнарын җәлеп итүгә тыю кертү турында**

«Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның $18^1$ статьясы 6 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъекты территориясендә эшчәнлек алып бара торган хуҗалык субъектларының үзләре файдалана торган чит ил хезмәткәрләре санын Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) тарафыннан расланган әлеге хуҗалык субъектларына карата патентлар нигезендә икътисадый эшчәнлекнең аерым төрләре буенча хезмәт эшчәнлеге алып бара торган чит ил гражданнарын җәлеп итүгә кертелгән тыюга туры китерү вакытын билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 7 декабрендәге 1327 номерлы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара торган хуҗалык субъектларына 2025 елның 31 декабренә кадәр, бу көнне кертеп, патентлар нигезендә Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторында (алга таба – ИЭТГК) күрсәтелгән түбәндәге икътисадый эшчәнлек төрләре буенча хезмәт эшчәнлеге алып бара торган чит ил гражданнарын җәлеп итү тыела:

куркынычлы йөкләрне ташу (ИЭТГК буенча коды 49.20.1);

җиңел автомобильләрдә такси хезмәте күрсәтү һәм автомобиль йөртүчеләре белән бергә җиңел автомобильләрне арендага бирү эшчәнлеге (ИЭТГК буенча коды 49.32);

иминиятләштерү һәм пенсия тәэминаты хезмәтләреннән тыш, финанс хезмәте күрсәтү эшчәнлеге (ИЭТГК буенча коды 64);

мәҗбүри социаль тәэминаттан тыш, иминиятләштерү, яңадан иминиятләштерү, дәүләтнеке булмаган пенсия фондлары эшчәнлеге (ИЭТГК буенча коды 65);

финанс хезмәтләре һәм иминиятләштерү өлкәсендә ярдәмче эшчәнлек (ИЭТГК буенча коды 66);

хокук һәм бухгалтерлык исәбе өлкәсендә эшчәнлек (ИЭТГК буенча коды 69);

ветеринария эшчәнлеге (ИЭТГК буенча коды 75);

сак хезмәтләре, шул исәптән хосусый сак хезмәтләре (ИЭТГК буенча коды 80.10);

отышлы уеннар оештыру һәм уздыру, бәхәскә нигезләнгән килешүләр төзү, лотереяләр оештыру һәм уздыру эшчәнлеге (ИЭТГК буенча коды 92);

компьютерларны, шәхси кулланылыштагы һәм хуҗалык-көнкүреш билгеләнешендәге предметларны төзекләндерү (ИЭТГК буенча коды 95).

2. Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара торган хуҗалык субъектларына әлеге Указның 1 пунктында каралган икътисадый эшчәнлекнең һәр төре өчен үзләре файдалана торган чит ил хезмәткәрләре санын әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән тиешле туры китерү вакыты әлеге Указ үз көченә кергән көннән өч ай дип билгеләргә.

3. Әлеге Указ рәсми бастырып чыгарылган көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 29 гыйнвар
№ 57